ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында архив эше турында» Татарстан Республикасы Законының 21 һәм 22 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 56-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары М.Һ. Галиев, Р.Г. Хөсәенов тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында архив эше турында» Татарстан Республикасы Законының 21 һәм 22 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 56-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2025 елның 28 марты
№ 233-VII ДС

Проект

**«Татарстан Республикасында архив эше турында» Татарстан Республикасы Законының 21 һәм 22 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасында архив эше турында» 2017 елның 20 июлендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 55 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш); 2021, № 93 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 92 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 21 статьяда:

а) 2 өлештә:

1 пунктта «электрон документ рәвешендә» сүзләрен «электрон рәвештә» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктта «электрон документ рәвешендә» сүзләрен «электрон рәвештә» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 4 өлеш өстәргә:

«4. Архив эше өлкәсендә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы һәм җирле үзидарә органнары архив документлары һәм аларга белешмә-эзләү чаралары белән ерактан торып эшли һәм алардан ерактан торып файдалана алу хезмәтен (алга таба – архив документларыннан ерактан торып файдалану хезмәте) күрсәтү өчен кирәкле оештыру-техник һәм башка шартлар булдырырга хокуклы.»;

2) 22 статьяга түбәндәге эчтәлекле 6 – 8 өлешләр өстәргә:

«6. Татарстан Республикасы дәүләт архивлары саклавындагы архив документларыннан ерактан торып файдалану хезмәтен күрсәтү архив эше өлкәсендәге Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы ярдәмендә тәэмин ителә.

7. Муниципаль архивлар аларның саклавында булган архив документларыннан ерактан торып файдалану хезмәтен архив эше өлкәсендәге Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы ярдәмендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә күрсәтергә хокуклы.

8. Архив документларыннан ерактан торып файдалану хезмәтен Татарстан Республикасы Архив фонды составына керә торган, архив тарафыннан электрон рәвешкә күчерелгән архив документларының электрон күчермәләрен карау һәм (яисә) тыңлау өлешендә күрсәткән өчен архив документларыннан файдаланучылардан түләү алынырга мөмкин. Күрсәтелгән хезмәтне архив эше өлкәсендәге Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы ярдәмендә күрсәткән өчен түләү күләме, мондый түләүне алу тәртибе һәм очраклары Татарстан

Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә. Архив эше өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында архив документларыннан файдаланучыларны теркәгән, шулай ук архив эше өлкәсендәге Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында булган белешмә-эзләү чараларыннан файдаланган өчен түләү алынмый.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында архив эше турында» Татарстан Республикасы Законының 21 һәм 22 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законы проектына аңлатма**

«Татарстан Республикасында архив эше турында» Татарстан Республикасы Законының 21 һәм 22 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты «Россия Федерациясендә архив эше турында» Федераль законның 24 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 13 декабрендәге 469-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон) кабул ителүгә бәйле рәвештә эшләнде.

Федераль закон электрон рәвештәге архив документларыннан файдалану тәртибен камилләштерүгә юнәлдерелгән. Аерым алганда, нигезләмәсе Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланырга тиешле яңадан төзелә торган дәүләт мәгълүмат системасы йә тиешенчә Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актларында һәм муниципаль хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә региональ дәүләт мәгълүмат системалары һәм муниципаль мәгълүмат системалары ярдәмендә Россия Федерациясе субъектларының дәүләт архивлары һәм муниципаль архивлар тарафыннан аларның саклавында булган архив документларыннан һәм аларга белешмә-эзләү чараларыннан ерактан торып файдалану хезмәтен күрсәтү мөмкинлеге каралды.

Татарстан Республикасында архивларда булмыйча гына архив мәгълүмат ресурсларыннан файдалану һәм дәүләт хезмәтләрен күрсәтү буенча һәркем файдалана алырлык сервис – «Татарстан Республикасы бердәм архив мәгълүмат системасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы (алга таба – Бердәм архив мәгълүмат системасы) төзелде. Бердәм архив мәгълүмат системасы турында нигезләмә һәм Бердәм архив мәгълүмат системасыннан файдаланучыларның мәгълүмати хезмәттәшлеге регламенты 2018 елның 22 сентябрендәге 836 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланды.

Республика законнары нигезләмәләрен Федераль законга туры китерү максатларында закон проекты белән «Татарстан Республикасында архив эше турында» Татарстан Республикасы Законының 21 һәм 22 статьяларына Татарстан Республикасы дәүләт архивлары һәм муниципаль архивлар саклавындагы архив документларыннан Бердәм архив мәгълүмат системасы ярдәмендә ерактан торып файдалану хезмәтен күрсәтү тәртибен төгәлләштерүгә юнәлдерелгән үзгәрешләр кертү тәкъдим ителә.

**«Татарстан Республикасында архив эше турында» Татарстан Республикасы Законының 21 һәм 22 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатып торылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары исемлеге**

«Татарстан Республикасында архив эше турында» Татарстан Республикасы Законының 21 һәм 22 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарының үз көчләрен югалтуын тануны, аларны туктатып торуны, үзгәртүне яисә башкаларын кабул итүне таләп итми.

«Татарстан Республикасында архив эше турында» Татарстан Республикасы Законының 21 һәм 22 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү архив эше өлкәсендәге Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында архив документларыннан ерактан торып файдалану хезмәтен күрсәткән өчен түләү алу тәртибен һәм очракларын, шулай ук аның күләмен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән билгеләүне таләп итәчәк.

**«Татарстан Республикасында архив эше турында» Татарстан Республикасы Законының 21 һәм 22 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын финанс-икътисадый нигезләү**

«Татарстан Республикасында архив эше турында» Татарстан Республикасы Законының 21 һәм 22 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән каплана торган өстәмә чыгымнарны таләп итми.